Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

21 октябрь, 2020 ел № 7

Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге уставының 23 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Питрәч авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 19 ноябрендәге 146 номерлы Питрәч авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Питрәч авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1.Олан Иле авылында. Гражданнар җыенын дүрт этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабын 2020 елның 6 ноябрендә иртәнге 10.00 сәгатьтә Кояшлы урамы, 7А йорты буенча «Авокадо» кибете янында үткәрергә. Җыенда катнашучылар исемлегенә Яңа, Эксперименталь урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабын 2020 елның 6 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Кояшлы урамы, 7А йорты буенча «Авокадо» кибете янында үткәрергә. Җыенда катнашучылар исемлегенә Тау асты, Пионер, Федосеев урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының өченче этабын 2020 елның 7 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Кояшлы урамы, 7А йорты буенча «Авокадо» кибете янында үткәрергә. Җыенда катнашучылар исемлегенә Кояшлы урамы буенча теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының дүртенче этабын 2020 елның 7 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Кояшлы урамы, 7А йорты буенча «Авокадо» кибете янында үткәрергә. Җыенда катнашучылар исемлегенә Үзәк, Луговая урамнары буенча теркәлгән халыкларны кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2021 елда Олан Иле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, Чернобыль АЭСын бетерү катнашучылары, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне, бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- чишмә территориясен төзекләндерү
- чишмәгә юлны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Шихазда авылында. Гражданнар җыенын ике этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабын 2020 елның 9 ноябрендә Үзәк урамы, 51 йорт буенча 17.30 сәгатьтә авыл клубы бинасында үткәрергә. Җыенда катнашучылар исемлегенә Үзәк урамы буенча теркәлгән халыкны кертергә;
- гражданнар җыенының икенче этабын 2020 елның Үзәк урамы, 51 йорт буенча 17.30 сәгатьтә авыл клубы бинасында үткәрергә. Җыенда катнашучылар исемлегенә Тау асты, Шоссе урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2021 елда Шихазда торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, Чернобыль АЭСын бетерү катнашучылары, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне, бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- зиратка юлны ремонтлау
- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Питрәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы И.М. Кашапов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ПЕСТРЕЧИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1633000000